***РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН***
ГЛАВА
Балтачевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Молодежная, д.1А, с. Балтач, 423302
Азнакаевского муниципального района
Тел. (8-5592) 44-7-23,
**Balt.Azn@tatar.ru**

***ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ***
Азнакай
муниципаль районы Балтач авыл җирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

Яшьлэр урам, 1А, Балтач авылы, 423302
Тел. (8-5592) 44-7-23
**Balt.Azn@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» ноябрь 2023 ел. №5

Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы,
Балтач авылы, Узэк урамы, 41 йорт,
адреслары буенча урнашкан җир кишәрлеген шартлы
рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар
проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча Балтач авыл җирлегендә яшәүчеләрнең яшәү шартлары, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре уңай шартларын үтәү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Балтач авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре, Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә **карар бирә**:

1. Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы, Узэк урамы, 41 йорт адресы буенча урнашкан 5573,54 кв.м.мәйданлы 16:02:060101:18 кадастр номерлы булган - бакчачылык алып бару (код 13.1) - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1).

2. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын оештыручы итеп - Балтач авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;

- үткәрү вакыты - 2023 елның 11 декабрдән 2023 елның 26 декабренә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны – Балтач авылы, Яшьлэр урам, 1А йорт адресы буенча урнашкан Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы.

- 2023 елның 26 декабренә кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Балтач авылы, Яшьлэр урамы, 1А, Азнакай муниципаль районының Балтач авылы җирлеге Башкарма комитеты.

3. Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 12 декаберенэ кадәр, җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турындагы хәбәрләрне җибәрергә;

- җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында нәтиҗә әзерләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Л.Л.Хәбипов